ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

№269

«22» 05 2025 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру схемасы килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген раслау турында

"Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль законның 9 өлешендәге 18 статьясы, "Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру схемасы килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 22.05 269 номерлы карарына кушымта.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру схемасы килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеге

1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Спас районы буенча бүлегенең дәүләт автоинспекциясе бүлеге (килешү буенча).

2. Автомобиль юллары хуҗасы йә татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Юл хәрәкәтен оештыру схемасы эшләнә торган җирле әһәмияттәге автомобиль юллары оператив идарәсендә булган орган.